ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.06.2024 ел Баулы шәһәре №80

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 31 июлендәге 159 номерлы карары белән расланган, торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Федераль законның 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 31 июлендәге 159 номерлы карары белән расланган, торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2 бүлектә «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартлары»:

2.7.1. пунктының 10) пунктчасында «Социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләрен «Социаль системада бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләре белән алмаштырырга;

3 бүлектә «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлеш вакыты, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре. Гомуми билгеләр белән берләшкән аерым категория мөрәҗәгать итүчеләргә күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү тәртибен үз эченә алган, шул исәптән алар алган муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә карата муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары. Муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буенча, гомуми билгеләр белән

берләшкән аерым категория мөрәҗәгать итүчеләргә күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү тәртибен үз эченә ала»:

3.6. пунктын 3.6.3., 3.6.4. пунктчалары белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«3.6.3. Әгәр бинаны торак яки торак булмаган бина буларак куллануны тәэмин итү өчен аны үзгәртеп кору, һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыру һәм (яисә) башка эшләр башкару таләп ителмәсә, Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясының 5 өлешендә каралган, торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерү турында карар кабул итүне раслаучы документ Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры мәгълүматларына үзгәрешләр кертү өчен нигез булып тора. Бу очракта әлеге күчерү мондый бинаның билгеләнеше турында күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестры мәгълүматларына тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән тәмамланган дип санала.

3.6.4. Әлеге регламентның 2.3.1 пунктчасында күрсәтелгән үзгәртеп кору, һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыру һәм (яисә) башка эшләрнең тәмамлануы турында хәбәрнамәне гариза бирүче күрсәтелгән күчерелә торган бинаның урнашкан урыны буенча турыдан-туры яисә күпфункцияле үзәк аша Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелгән үзара хезмәттәшлек турында килешүгә ярашлы рәвештә күчерүне гамәлгә ашыручы органга җибәрә. Бинаны үзгәртеп планлаштыру очрагында мондый хәбәр итүгә бинаның техник планы кушыла, аңа карата үзгәртеп планлаштыру гамәлгә ашырыла. Әлеге регламентның 2.3.1 пунктчасында күрсәтелгән үзгәртеп кору, һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру, һәм (яки) башка эшләрнең тәмамлануы биналарны күчерүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан формалаштырылган кабул итү комиссиясе акты белән раслана (алга таба - кабул итү комиссиясе акты).

Кабул итү комиссиясенең актын раслау, Бүлек әлеге өлештә күрсәтелгән хәбәрнамәне алганнан соң, утыз көннән дә артмаган вакытта гамәлгә ашырыла. Торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерү, аны гамәлгә ашыру өчен бинаны күчерү турында карар кабул итүне раслаучы документ нигезендә үзгәртеп кору һәм (яки) башка эшләр башкару таләп ителгән, бинаны билгеләү турында күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестры мәгълүматларына үзгәрешләр кертелгән көннән тәмамланган дип санала.

Торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерү, аны гамәлгә ашыру өчен, карар кабул итүне раслаучы документ нигезендә, бинада яңадан планлаштыру (перепланировка) таләп ителгән булса, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестры мәгълүматларына мондый бинаның чикләре һәм (яки) мәйданы һәм билгеләнеше турында үзгәрешләр кертелгәннән соң яисә барлыкка килгән биналарны

дәүләт кадастр исәбен һәм дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру көненнән тәмамланган дип санала.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы рәсми сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров